Әлбәттә, тотсыннар. Шушы тоткан уразалары бәрәкәтендә иман-ихласлары артып, Аллаһы рәхмәте белән намазга да басарлар. Аллаһы Сүбхәнәһү вә Тәгалә Коръән-Кәримендә безгә җиңеллек тели, авырлык теләми. һәрбер нәрсәнең пычрагы була. Без күңелебездә булган кайбер кара нәрсәләрне Аллаһыга зикер белән, тәсбих, намаз белән чистартабыз. Тәннәребездәге кирәкмәгән нәрсәләрне елның бер аенда ураза тотып чистартабыз. Ләкин без фарыз, нәфел рузаларны бөер-бавырларны чистарту өчен түгел, ә Аллаһы риза булсын дигән ният белән тотабыз. Рамазан аенда ураза тоткан бәндәләргә күп-күп сөенечле вәгъдәләр бар. Ә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән күркәм вәгъдәләрнең иң зурысы: «*Рамазан аенда ураза тотучының тоткан уразасы кабул булса, анадан яңа туган бала шикелле гөнаһсыз булып калыр*», – диелгән Рәсүлебезнең хәдис-шәрифендә. Бу - бик зур сөенеч.

Аллаһы Сүбхәнәһү вә Тәгалә илләребезгә-көннәребезгә иминлекләр, тынычлыклар бирсен, авыруларга хәерле шифалар насыйп әйләсен. Рамазан аенда нәфел садакалар, фитыр садакасы һәм зәкят бирү бар. Алар мескеннәр, ятимнәр, гарип-горабалар, тол хатыннар һәм күп балалы гаиләләргә ярдәм итү өчен биреләләр. Мөхтәрәм газиз кардәшләр, изгелек аенда изгелекләрне арттырыйк. Күңелебездә нинди пычрак, хөсетлек, ачулар булса, аларны бетерик, бер-беребезне гафу итик. Бу - гафу итү ае. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саләллаһү галәйһи вә сәлләм безгә Кадер кичәсендә укыла торган шушы доганы өйрәтте: *«Әллааһүммә әңтә гәфүвүн. Түхиббүл гәфвә. Фәгфү гәннәә»* – *«Йә, Раббым, Син гафу итүче зат, гафу итүне сөясең. Гөнаһларыбызны гафу ит»*. Рамазан ае бәрәкәтендә барча гөнаһларыбыздан арынырга насыйп булсын иде.

**Мөфти Госман хәзрәт ИСХАКЫЙ.**
**(“Татар дини календаре”ннан)**

---

***20 ИЮЛЬДӘ УРАЗА БАШЛАНДЫ***

# Сабырлык ае

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Ислам дөньясы бар булмышы һәм ихласлыгы белән динебезенең төп биш шартыннан берсе булган ураза гыйбадәтен үтәүдә хозурлык кичерә. Елына бер генә тапкыр килә торган шушы фарыз гамәл - Рамазан аенда ураза тоту - аеруча зур әзерлек белән көтеп алына. Гыйбадәтләрнең асылы булган ураза шартлары хакында бер-ике сүз белән генә аңлатып бирү мөмкин түгел. Монда Аллаһы Тәгаләнең бик зур һәм күп хикмәтләре бар. Ураза – Раббыбыз тарафыннан фарыз кылынган олуг гыйбадәт. Без аны бары тик Аның ризалыгы өчен генә үтәргә тырышабыз. Хак Тәгалә: «Адәм баласының уразадан башка һәр эше (гыйбадәте) үзе өчен. Ләкин ураза – Минем өчен һәм аның савабын да (әҗерен) Мин үзем бирәчәкмен», – ди. Ураза тоткан кешенең уразалы булуын Аллаһыдан башка беркем белмәс. Динебездә аңлатылуынча, уразаның савабы да шуңа күрә чиксез. Ләкин шушы айда безнең тәкъвалыгыбызны сынап кына калмый Тәңребез, шул ук вакытта бу ай эчендә бик күп хикмәтләр һәм могҗизалар да яшерелгән. Аның бәндәләргә матди яктан да, мәгънәви яктан да бик күп файдалары бар.*

## Уразаның файдалары

Ураза тоткан кеше иң беренче үзенә хаким булырга өйрәнә. Ул көне буе гыйбадәт хәлендә була. Чөнки мәгълүм булганча, ураза – ач тору һәм сусыз калу гына түгел әле. Пәйгамбәребез (с.г.в.с.): *«Бары тик ашказанына гына ураза тоттырмагыз. Барча әгъзаларыгызга да ураза тоттырыгыз»,* – дигән. Ягъни кеше үзен әхлакый яктан да тәрбияли: ямьсез сүзләрдән, ялганнан, гайбәттән, яла ягу һәм сүз йөртү кебек бәндәчелек хаталарыннан тыела. Ураза тоткан кеше күзен, колагын, аяккулларын да начар эшләрдән саклар. Сәүдә эшендә гадел булыр, ярлыларга ярдәм итәр, өлкәннәргә – хөрмәт, кечкенәләргә дә шәфкать һәм мәрхәмәт күрсәтер, дип аңлатыла дини чыганакларда.

## Нәфес белән сугыш

Ураза тоткан кеше нәфесе ни кушса, шуны эшләмәс, ягъни нәфесенең тоткыны булмас. Урынсыз теләкләренә ирек куймас. Сабыр булырга өйрәнер. Үзендә ихтыяр көчен күрсәтер һәм тәрбияләр. Бу җәһәттән Пәйгамбәребез (с.г.в.с.) әйтеп калдырган сүзләрне китерү мөһимрәк булыр. Мәнкәле көферләр арасында булган бер сугышта мөселманнар, көферләрне җиңеп, бик шатланып Мәдинә шәһәренә кайткач, Пәйгамбәребез (с.г.в.с.) гаскәрләренә болай дигән: «*Хәзер без кечкенә сугышта җиңдек. Моннан соң зур сугышны да җиңәргә тырышыгыз*». Аның бу сүзләреннән гаҗәпләнгән мөселманнар: «*Я, Рәсүлуллаһ, моннан да зуррак сугыш булырмы соң? Без бит иң зур сугышта җиңдек дошманнарыбызны*», – дип сораганнар. Шул вакытта Пәйгамбәребез (с.г.в.с.): «*Иң зур сугыш – кешенең үз нәфесенә каршы, ягъни эчендәге начар ният-теләкләренә каршы сугыш ул*», – дигән. Чынлап та, кешенең эчендә бу теләкләрне эшләргә өндәп торучы бер көч, куәт бар ич. Динебез әмерләреннән берсе – әнә шушы көчкә каршы тору. Ә ураза тоткан кеше нәфесенең начар теләкләренә каршы тора, ихтыяр көчен ныгыта. Шуңа күрә дә Пәйгамбәребез (с.г.в.с.): *«Ураза – (кешене начар эшләрдән саклаган) бер калкандыр»*, – дигән.





# Барча кичәләрнең изгесе

Мөбарәк Рамазан аеның соңгы ун көнендә мөселман дөньясы фәрештәләр Җир йөзенә иңгән Кадер кичәсен билгеләп үтә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Кадер кичәсен Рамазанның ахыргы 10 көне арасыннан, бигрәк тә так санлы кичләреннән эзләгез»*, - дигән (иң ихтималы - 27 нче көн). Кадер кичәсе бигрәк тә ике мөһим вакыйга белән кадерле: шушы кичәдә хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Пәйгамбәрлек вазифасын үтәргә керешкән һәм аның аша кыямәт көненә кадәр бөтен кешелеккә ике җиһан сәгадәтен тәэмин итәчәк Коръән-Кәрим иңдерелә башлаган.

Әйе, моннан 1400 чамасы ел элек Рамазан аеның бер кичәсендә иман, әхлак вә гыйбадәттән мәхрүм калган кешелек дөньясы офыгында тәүхид (Аллаһының берлеге) нурының мәгърифәт факелы балкыды. Ул – «Укы!» дигән беренче әмере белән үк дөньяны караңгылык эчендә торган гафиллек болытларын бер мизгелдә алып ташлаган Коръән факелы булды. Коръән – адәм балаларына җаһиллек-наданлыктан, ялкаулыктан, тәкәбберлектән, масаюдан, саранлыктан, яла ягудан, ялганнан, хәмердән, отыш уеннарыннан, фәхешлектән, исрафчылыктан, мәгънәсезлектән, золымнан, фаиз (процент) алудан һәм бәндә хакын үзләштерүдән, кыскасы, адәм баласының матди вә рухый тынычлыгын, хозурлыгын бозарлык һәртөрле сүз һәм гамәлләрдән тыелырга боерган яшәеш конституциясе ул. Менә шул Коръән-Кәрим кояшы, ягъни ислам кояшы балкый башлаган кичәгә «Кадер кичәсе» диләр.

Бу кичә турында илаһи Кәлямдә болай диелгән: *«Без аны (Коръәнне) Кадер кичәсендә иңдердек. Кадер кичәсенең шәрәф вә кыйммәтен сиңа белдергән нидер? Кадер кичәсе мең айдан да хәерледер. Ул кичәдә Раббыларының рөхсәте белән фәрештәләр һәм рух (Җәбраил) һәр эш өчен (җиргә) иңеп торыр. Ул кичә (төн) таң беленә башлаганга кадәр сәлам вә сәламәт кичедер».*

Без дә Коръән иңгән бу кичәдә үз-үзебездән хисап алыйк. Бәндәчелек белән кылган гөнаһларыбыз өчен Аллаһыдан гафу итүен сорыйк, Коръән кысаларыннан беркайчан да чыкмаска сүз бирик. Бу изге көннәрне намаз укып, Коръән укып, зикер вә салават әйтеп, вәгазь вә нәсыйхәт тыңлап, дини китаплар укып үткәрик. Шундый рух һәм аң белән үткәргән Кадер кичәсе, иншаллаһ, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдис-шәрифендә вәгъдә ителгән бүләккә лаек булуыбызга форсат булыр. Пәйгамбәребез: *«Кем иманлы күңел белән һәм савабын фәкать Аллаһыдан өмет итеп Кадер кичәсен гыйбадәт (тәүбә-истигъфар, дога, зикер) белән үткәрсә, кылган гөнаһлары гафу ителер»*, - дигән.

- Бу кичә – дөнья һәм ахирәт арасында яшәгәннәрнең кичәседер.
- Бу кичә – кеше булып яшәүнең мәгънәсен һәм кадерен белгәннәрнең кичәседер.
- Бу кичә – нәфесен һәм шайтанны җиңеп илаһи әмергә инанганнарның кичәседер.
- Бу кичә – гафләт йокысыннан уянып, илаһи әмерләргә оеганнарның кичәседер.
- Бу кичә – ислам галәменә һәм дөньябызга тынычлык, хозурлык килүенә сәбәпче булган кичәдер.

**Әхмәд ШАҺИН, ислам дине белгече.**
**(“Дин вә йола” газетасыннан)**

---




**- Ураза тотарга ниятләүне кычкырып әйтергә кирәкме, әллә күңелдән генә хәл итәргәме?**

Күңел, уй белән ураза тотарга ниятләү - җитәрлек шарт. Ниятләүне тел белән әйтү дә яхшы, ләкин мәҗбүри түгел. Таң атканчы ниятләргә кирәк яки кояш батканнан соң, кичтән үк ниятләп куярга да ярый. Аллаһы Тәгаләнең соңгы Илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтүенчә, таң атканнан соң ниятләнгән ураза дөрес булмый. Дүрт мәзһәбнең өчесенең дин әһелләре ниятләүне көн саен кабатларга кирәк, дип саный. Ә мәлики мәзһәбе галимнәре ниятләүне бары бер генә тапкыр, Рамазан ае башланганда гына үтәү дә җитә, дип уйлыйлар.

*(“Дин вә йола” газетасыннан)*

* * *

**Без әле соңгы елларда гына ураза тота башладык. Ә калган уразаларны ничек каза кылырга икәнен белмибез. Аллаһы Тәгалә: “Теләгән бәндәмне туры юлга күндерермен”, -дип әйткән бит Коръәнендә.**

Әгәр дә сау-сәламәт булсагыз, гомер буена калган уразаларыгызны үтәп чыгыгыз. Аллаһы Тәгалә куәт-ярдәмен бирсен. Әйтик, сез 10 ел буена ураза тотмагансыз икән, 10 ай ураза тотарга тиеш буласыз, тик Рамазан ае җиткәч, шушы елның уразасына керерсез. Калган еллар уразасын үтәргә керешкәндә: “Йә, Раббым! Ният кылдым гомерем буена калган фарыз уразаларны үтәргә...” - дип ниятләргә онытмагыз. Ураза тотуның тәртип-кагыйдәләрен дә исегездә тоту хәерле. Әгәр авыру икәнсез, ул вакытта 10 еллык уразаны 300 көн тотарга тиеш буласыз. Әгәр ураза тотарга гаҗиз икәнсез, һәр көн өчен бер фәкыйрьне туендырырлык ризык яки ризык алырлык акча белән тәэмин итәргә тиеш буласыз...

Хаҗга баргач, без калган намазлар турында сораган идек. Галимнәр: «Үзегезне кайчаннан башлап мөселман дип санайсыз, сез шул көннән гамәлләрегезне төгәл үтәп барырга тырышыгыз», - дигәннәр иде. Бу бит инде безнең калган уразаларыбызга да кагыла. Бу очракта шул җавапларны күбрәк тыңларга кирәктер. Чөнки гомер буе калган гыйбадәтләребез һич үтәп бетерерлек түгел. Әлбәттә, үтәргә тырышырга кирәк.

**(“Татар мөселман календаре”ннан)**